ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 493-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 493-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2166-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кетрелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

**1 статья**

«Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләрне исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 22 декабрендәге 132 -ТРЗ номерлы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (II өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 10; 2014, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 кушымтада:
а) $1^2$ пунктта:
алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« $Ч^{i}_{ГПj}$ – i муниципаль районның җирле үзидарә органнары мәгълүматлары буенча чираттагы финанс елына һәм план чорына i муниципаль районның j-нче шәһәр җирлеге халкының фаразланган саны, тиешле елга i-нче муниципаль район халкының фаразланган саны турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисад өлкәсендә вәкаләтле органы мәгълүматлары нигезендә формалаштырыла;»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«n – i муниципаль район составына керүче шәһәр җирлекләре саны, чираттагы финанс елында һәм план чорында бюджетларыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр күчерү каралган шәһәр җирлекләреннән тыш.»;

б) $1^3$ пунктта:
алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« $Ч^{i}_{спj}$ – i муниципаль районның җирле үзидарә органнары мәгълүматлары буенча чираттагы финанс елына һәм план чорына i муниципаль районның j-нче авыл җирлеге халкының фаразланган саны, тиешле елга i-нче муниципаль район халкының фаразланган саны турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисад өлкәсендә вәкаләтле органы мәгълүматлары нигезендә формалаштырыла;»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«s – i муниципаль район составына керүче авыл җирлекләре саны, чираттагы финанс елында һәм план чорында бюджетларыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр күчерү каралган авыл җирлекләреннән тыш.»;

в) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль районнар арасында субвенцияләр, чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль районның чираттагы финанс елында һәм план чорында бюджетларыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр күчерү каралган шәһәр, авыл җирлекләреннән тыш, муниципаль районның җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисад өлкәсендә вәкаләтле органының тиешле елга муниципаль район халкының фаразланган саны турында мәгълүматы нигезендә формалаштырыла торган мәгълүматлары буенча, шәһәр, авыл җирлекләрендә яшәүчеләрнең фаразланган санынннан чыгып, бер кешегә исәпләп, бүленә.»;

г) 4 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« $Ч^{i}_{гпj}$ – i муниципаль районның җирле үзидарә органнары мәгълүматлары буенча чираттагы финанс елына һәм план чорына i муниципаль районның j-нче шәһәр җирлеге халкының фаразланган саны, тиешле елга i-нче муниципаль район халкының фаразланган саны турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисад өлкәсендә вәкаләтле органы мәгълүматлары нигезендә формалаштырыла;»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«n – i муниципаль район составына керүче шәһәр җирлекләре саны, чираттагы финанс елында һәм план чорында бюджетларыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр күчерү каралган шәһәр җирлекләреннән тыш.»;

д) 5 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« $Ч^{i}_{спj}$ – i муниципаль районның җирле үзидарә органнары мәгълүматлары буенча чираттагы финанс елына һәм план чорына i муниципаль районның j-нче авыл җирлеге халкының фаразланган саны, тиешле елга i-нче муниципаль район

халкының фаразланган саны турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисад өлкәсендә вәкаләтле органы мәгълүматлары нигезендә формалаштырыла;»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«s – i муниципаль район составына керүче авыл җирлекләре саны, чираттагы финанс елында һәм план чорында бюджетларыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр күчерү каралган авыл җирлекләреннән тыш.»;

2) 2 нче кушымтада:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары шәһәр җирлекләре бюджетларына дотацияләрне, әлеге Методиканың 2 пункты нигезендә халык саныннан чыгып, Татарстан Республикасы бюджетыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләрне исәпләп чыгару һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр (алга таба шулай ук - шәһәр җирлекләренә дотацияләр) бирү өчен каралган субвенциянең бер өлеше хисабына бүлеп бирәләр»;

Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләрне, әлеге Методиканың 10 пункты нигезендә халык саныннан чыгып, Татарстан Республикасы бюджетыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләрне исәпләп чыгару һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр (алга таба шулай ук - авыл җирлекләренә дотацияләр) бирү өчен каралган субвенциянең бер өлеше хисабына бүлеп бирәләр»;

б) 2 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« $Ч^{i}_{ГПj}$ – i муниципаль районның җирле үзидарә органнары мәгълүматлары буенча чираттагы финанс елына һәм план чорына i муниципаль районның j-нче шәһәр җирлеге халкының фаразланган саны, тиешле елга i-нче муниципаль район халкының фаразланган саны турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисад өлкәсендә вәкаләтле органы мәгълүматлары нигезендә формалаштырыла;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«n – i муниципаль район составына керүче шәһәр җирлекләре саны, чираттагы финанс елында (чираттагы финанс елында һәм план чорында) бюджетларыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр күчерү каралган шәһәр җирлекләреннән тыш.»;

в) 3 – 9 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) 10 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$Ч^{i}_{СПj}$ – i муниципаль районның җирле үзидарә органнары мәгълүматлары буенча чираттагы финанс елына һәм план чорына i муниципаль районның j-нче авыл җирлеге халкының фаразланган саны, тиешле елга i-нче муниципаль район халкының фаразланган саны турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисад өлкәсендә вәкаләтле органы мәгълүматлары нигезендә формалаштырыла;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«s – i муниципаль район составына керүче авыл җирлекләре саны, чираттагы финанс елында (чираттагы финанс елында һәм план чорында) бюджетларыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр күчерү каралган авыл җирлекләреннән тыш.»;

д) 11 – 17 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танылырга;

е) 19 пунктның алтынчы абзацында «чираттагы финанс елына» сүзләрен «чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 20 пунктның алтынчы абзацында «чираттагы финанс елына» сүзләрен «чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 нче кушымтадагы таблицада «Җирлектә яшәүчеләр саны» сүзләрен «Җирлектә яшәүчеләрнең ___ елга фараз саны» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 12 (I өлеш; 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2019, № 19 (I өлеш); № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$Ч_i$ – i муниципаль берәмлектә муниципаль комиссия белгечләренең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә билгеләнә торган норматив саны.»;

2) 4 пунктның дүртенче – алтынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$Z_i$ – i муниципаль берәмлектә муниципаль комиссиянең бер белгече хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән норматив чыгымнар:

«баш белгеч» - балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссиянең җаваплы секретаре өчен;

«әйдәп баручы белгеч» - балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссия белгече өчен;».

**3 статья**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, №12 (IV өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның бишенче абзацына «әлеге Законның 12 статьясының 2 өлеше нигезендә аның составына даими штат нигезендә кергән» сүзләрен өстәргә;

2) 4 пунктның дүртенче абзацында «чыгымнар» сүзен «норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. i муниципаль берәмлектә муниципаль комиссиянең бер белгеченең хезмәт хакына норматив чыгымнар Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән «баш белгеч» вазыйфасы буенча һәм i муниципаль берәмлеккә агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган күрсәтелгән чыгымнар күләменнән чыгып, чираттагы финанс елына һәм план чорына хезмәт хакын арттыру индексларын кулланып исәпләнә.».

**4 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 7 (II өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$Чр_i$ – i муниципаль берәмлектә белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы

белгечләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә торган норматив саны;»;

2) 9 пунктның дүртенче абзацында «чыгымнар» сүзен «норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

3) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. i муниципаль берәмлегендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәт хакына норматив чыгымнар Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә, «Казан шәһәре» шәһәр округыннан тыш, i муниципаль берәмлек өчен 1 штат берәмлеге һәм «Казан шәһәре» шәһәр округы өчен 10 штат берәмлеге исәбеннән «баш белгеч» вазыйфасы буенча билгеләнә һәм i муниципаль берәмлегенә агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган күрсәтелгән чыгымнар күләменнән чыгып, чираттагы финанс елына һәм план чорына хезмәт хакын арттыру индексларын кулланып исәпләнә.».

**5 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 16 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымтаның 3 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, N 7 (I өлеш); 2013, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$H_{i1}$ – чираттагы финанс елына һәм план чорына i муниципаль берәмлек халкының Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисад өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан фаразланган саны, тиешле елга;»;

2) бишенче абзацта «тиешле финанс елына» сүзләрен «чираттагы финанс елына һәм план чорына» сүзләренә алмаштырырга.

**6 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 7 апрелендәге 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 4; 2010, № 7 (II өлеш); 2013,

№ 10; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2019 № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Пкжит$_i$ – i муниципаль берәмлектә 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге халык саны, Россия Федерациясендә социаль, икътисади, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистик мәгълүмат формалаштыру функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы мәгълүматлары буенча, агымдагы финанс елына кадәрге елның 1 гыйнварына.»;

2) 5 пунктның дүртенче абзацында «чыгымнар» сүзен «норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

3) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. i муниципаль берәмлегендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәт хакына норматив чыгымнар Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә, «Казан шәһәре» шәһәр округыннан тыш, i муниципаль берәмлек өчен 1 штат берәмлеге һәм «Казан шәһәре» шәһәр округы өчен 5 штат берәмлеге исәбеннән «баш белгеч» вазыйфасы буенча билгеләнә һәм i муниципаль берәмлегенә агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган күрсәтелгән чыгымнар күләменнән чыгып, чираттагы финанс елына һәм план чорына хезмәт хакын арттыру индексларын кулланып исәпләнә.».

**7 статья**

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 28 апрелендәге 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның 3 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 4; 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 3 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Д – «әйдәп баручы белгеч» вазыйфасы буенча елына Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә торган бер хезмәткәрнең хезмәт хакына норматив чыгымнар;»;

2) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ч – чираттагы финанс елына һәм план чорына «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге халкының саны, тиешле елга икътисад өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан фаразлана.».

**8 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итү белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 92 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш), 2023, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« $K_i$ – муниципаль берәмлектә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә торган норматив саны.»;

2) 4 пунктның дүртенче абзацында «чыгымнар» сүзен «норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. i муниципаль берәмлегендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәт хакына норматив чыгымнар Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә «баш белгеч» вазыйфасы буенча билгеләнә һәм i муниципаль берәмлегенә агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган күрсәтелгән чыгымнар күләменнән чыгып, чираттагы финанс елына һәм план чорына хезмәт хакын арттыру индексларын кулланып исәпләнә.».

**9 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 3; 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2019, № 28 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтада:

а) 3 пунктның дүртенче абзацында «чыгымнар» сүзен «норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. i муниципаль берәмлектә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәт хакына норматив чыгымнар Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә «баш белгеч» вазыйфасы буенча билгеләнә һәм i муниципаль берәмлеккә агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган күрсәтелгән чыгымнар күләменнән чыгып, чираттагы финанс елына һәм план чорына хезмәт хакын арттыру индексларын кулланып исәпләнә.

i муниципаль берәмлектә балигъ булмаганнарга карата дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең норматив саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән балигъ булмаган халык саныннан (0 яшьтән 18 яшькә кадәр), аларга карата опека билгеләнгән балигъ булмаганнар саныннан һәм тәрбиягә бала алган гаиләләргә тапшырылган балигъ булмаганнар саныннан чыгып билгеләнә.

i муниципаль берәмлекнең балигъ булмаган халкы саны Россия Федерациясендә социаль, икътисади, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистик мәгълүматны формалаштыру функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы мәгълүматлары буенча агымдагы финанс елына кадәрге елның 1 гыйнварына билгеләнә.

Опека билгеләнгән балигъ булмаганнар һәм тәрбиягә бала алган гаиләләргә тапшырылган балигъ булмаганнар саны агымдагы финанс елының 1 гыйнварына башкарма хакимиятнең гомуми белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен һәм норматив-хокукый җайга салуны эшләү һәм гамәлгә ашыру функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль органы федераль статистик күзәтүе мәгълүматлары нигезендә билгеләнә.»;

2) 2 нче кушымтада:

а) 3 пунктның бишенче абзацында «вазыйфалар саны» сүзләрен «норматив сан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$З_i$ – i муниципаль берәмлектә эшкә сәләтсезләргә карата дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бер хезмәткәрнең хезмәт хакына норматив чыгымнар;»;

в) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. i муниципаль берәмлектә эшкә сәләтсезләргә карата дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бер хезмәткәрнең хезмәт хакына норматив чыгымнар Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә «баш белгеч» вазыйфасы буенча билгеләнә һәм i муниципаль берәмлеккә агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган күрсәтелгән чыгымнар күләменнән чыгып, чираттагы финанс елына һәм план чорына хезмәт хакын арттыру индексларын кулланып исәпләнә.

i муниципаль берәмлектә эшкә сәләтсезләргә карата дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең норматив саны Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән і муниципаль берәмлекнең өлкән яшьтәге халкы санынннан чыгып билгеләнә.

Муниципаль берәмлекнең өлкән яшьтәге халкы саны социаль, икътисади, демографик, экологик һәм Россия Федерациясендәге башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистик мәгълүмат формалаштыру функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы мәгълүматлары буенча агымдагы финанс елына кадәрге елның 1 гыйнварына торышта билгеләнә.»;

г) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. і муниципаль берәмлектә эшкә сәләтсезләргә карата дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бер хезмәткәрне матди тәэмин итү чыгымнары і муниципаль берәмлеккә агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган матди тәэмин итүгә чыгымнар күләменнән чыгып, чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясенең социаль-икътисади үсеш фаразының төп күрсәткечләре нигезендә индекс-дефляторларны кулланып исәпләнә.»;

3) 3нче кушымтада:

а) 2 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$К_{1i}$ – опекага (попечительлеккә) бирелгән мәктәпкәчә яшьтәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның і-муниципаль берәмлектә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елы алдыннан булган тәгәлләнгән соңгы ике финанс елында і-муниципаль берәмлектә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә әлеге категориядәге балаларның уртача еллык саны кебек билгеләнә торган саны;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$К_{2i}$ – опекага (попечительлеккә) бирелгән мәктәп яшендәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның і-муниципаль берәмлектә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елы алдыннан булган тәгәлләнгән соңгы ике финанс елында і-муниципаль берәмлектә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә әлеге категориядәге балаларның уртача еллык саны кебек билгеләнә торган саны;»;

б) 3 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$К_{1i}$ – тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән мәктәпкәчә яшьтәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның і-муниципаль берәмлектә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан

билгеләнә торган чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елы алдыннан булган төгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлектә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә әлеге категориядәге балаларның уртача еллык саны кебек билгеләнә торган саны;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$К_{2i}$ – тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән мәктәп яшендәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның i-муниципаль берәмлектә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елы алдыннан булган төгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлектә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә әлеге категориядәге балаларның уртача еллык саны кебек билгеләнә торган саны;»;

в) 4 пунктта:

бишенче-сигезенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$К_{1i}$ – тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән мәктәпкәчә яшьтәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның i-муниципаль берәмлектә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елы алдыннан булган төгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлектә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә әлеге категориядәге балаларның уртача еллык саны кебек билгеләнә торган саны;»;

$К_{2i}$ – тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән мәктәп яшендәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның i-муниципаль берәмлектә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елы алдыннан булган төгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлектә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә әлеге категориядәге балаларның уртача еллык саны кебек билгеләнә торган саны;»;

$К_{3i}$ – балигъ булмаган гражданнарга хәрби әзерлек үткәрүгә юнәлдерелгән өстәмә белем бирү программалары булган федераль дәүләт мәгариф оешмаларында укый торган, тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның i-муниципаль берәмлектә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елы алдыннан булган төгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлектә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында җирле үзидарә органнары

белешмәләре нигезендә әлеге категориядәге балаларның уртача еллык саны кебек билгеләнә торган саны;»;

$К_{4j}$ – тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән өч яшькә җитмәгән ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның яки ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кертелә торган инвалид балаларның йә психик яисә физик үсешендә кимчелекләр булган балаларның, яки девиант холыклы балаларның i-муниципаль берәмлектә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елы алдыннан булган тәгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлектә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә әлеге категориядәге балаларның уртача еллык саны кебек билгеләнә торган саны;»;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$К_{5j}$ – i-муниципаль берәмлектә педагогик яисә медицина белеме булган опекуннарның яисә попечительләрнең i-муниципаль берәмлектә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елы алдыннан булган тәгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлектә әлеге опекуннар һәм попечительләрнең факттагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә әлеге опекуннар һәм попечительләрнең уртача еллык саны кебек билгеләнә торган саны;»;

**10 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның бишенче абзацында «финанс» сүзен алып ташларга;

2)

3) 4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$Z_i$ – айга бер хезмәткәрнең хезмәт хакына Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә «баш белгеч» вазыйфасы буенча билгеләнә торган норматив чыгымнар.».

**11 статья**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1; 2013, № 5, № 10; 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2020, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 пунктта:

а) 1 пунктчаның дүртенче абзацына «агымдагы финанс елының 1 гыйнварына милек мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы мәгълүматлары буенча» сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктның дүртенче абзацына «агымдагы финанс елының 1 гыйнварына милек мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы мәгълүматлары буенча» сүзләрен өстәргә;

2) 13 пунктның дүртенче абзацына «агымдагы финанс елының 1 гыйнварына Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистик мәгълүмат формалаштыру функцияләрен башкаручы башкарма хакимиятнең федераль органы мәгълүматлары буенча» сүзләрен өстәргә.

**12 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) « $O_i$ – i муниципаль районда дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бер хезмәткәрнең «1 категорияле белгеч» вазыйфасы буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакына түләүгә норматив чыгымнар, бер елга исәптә;»;

2) 5 пунктның алтынчы абзацында «финанс» сүзен алып ташларга.

**13 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның алтынчы абзацына «агымдагы финанс елының 1 гыйнварына җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы мәгълүматлары буенча» сүзләрен өстәргә;

2) 4 пунктта:

а) бишенче абзацта «j муниципаль районы башкарма комитетының баш белгече тарафыннан» сүзләрен алып ташларга;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$Z_1$ - бер эш көне өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә «баш белгеч» вазыйфасы буенча билгеләнә торган хезмәт өчен түләүгә исәпләүләр белән хезмәт өчен түләүгә норматив чыгымнар.».

**14 статья**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яисә тирә-юньдә ориентлашу сәләтен югалткан затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2017 елның 10 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның 3 пунктына (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 52 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) дүртенче абзацта «хезмәт» сүзләре алдыннан «чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә торган» сүзләрен өстәргә;

2) бишенче абзацка «чираттагы финанс елына һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

3) алтынчы абзацка «чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә торган» сүзләрен өстәргә;

4) җиденче абзацта «көннәр саны» сүзен «календарь көннәр саны» сүзләренә алмаштырырга.

**15 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль районнар һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2020 елның 21 июлендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2020, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$Ч_i$ - агымдагы финанс елының 1 сентябренә җирле үзидарә органнары тарафыннан планлаштырылган i муниципаль берәмлектәге муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучылар саны;»;

2) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Р - чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән расланган уку чорында бер укучыга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына көненә туклану белән тәэмин итү бәясе нормативы;».

**16 статья**

1. Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның нигезләмәләре 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 елларның (2024 елга) план чорына бюджетлардан башлап Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә карата кулланыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү өлкәсендә республика законнарын камилләштерү максатларында эшләнде.

Закон проектының нигезләмәләре Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү өчен тәкъдим ителгән хокукны куллану практикасына нигезләнә. Үзгәрешләр Татарстан Республикасы бюджеты акчалары финанс тәэмин итү чыганагы булган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү методикасы нигезләмәләренә кагыла.

Кертелә торган үзгәрешләр белән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субвенцияләр күләмен исәпләү методикаларында булган формулалардагы аерым компонентларның эчтәлегенә төгәллекләр кертү тәкъдим ителә. Исәпләгәндә кулланыла торган мәгълүмат чыганаклары буларак, аерым алганда, статистика органнарының халык саны турында мәгълүматлары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан формалаштырыла торган халык саны турында фаразланган күрсәткечләр, шул исәптән халыкның аерым категорияләре буенча, норматив күрсәткечләрне, шул исәптән чыгымнар нормативларын, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләр саны нормативларын раслаучы Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары күрсәтелә.

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү субвенцияләр рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар күләмен исәпләүнең ачыклыгын арттыру өчен өстәмә хокукый нигезләр булдырачак.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларны кабул итүен таләп итәчәк:

«Мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы белгечләрнең норматив санын раслау турында»;

«Балигъ булмаган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең норматив санын раслау турында»;

«Суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки чикләнгән күләмдә эшкә сәләтле дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең норматив санын раслау турында»;

«Муниципаль берәмлектә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итү белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләр санын һәм вазыйфаларын билгеләү турында».

Шулай ук, үзләренә карата муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган түләмә чире каберлекләре һәм биотермик чокырлар исемлеген актуальләштерү һәм аларның мәйданнарын күрсәтү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 21 апрелендәге 620-р номерлы карарына үзгәрешләр кертү таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетының өстәмә чыгымнарын таләп итмәячәк.